Минем һөнәри осталыгым эссе

Балык Бистәсе муниципаль районы "Балык Бистәсе 2 нче номерлы гомуми урта белем бирүмәктәбе"МГББУукытучысы
Хафизова Рәсимә Миннулла кызы

Укытучы! Кем генә бу исемне зур хөрмәт белән телгә алмый икән? Һәркайсыбызның иң матур хәтирәләре, шатлык-борчулары, беренче дулкынланулары нәкъ менә мәктәп һәм укытучы белән бәйле. Беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап кергән көннән алып, бала белән янәшәдә аның укытучысы атлый. Бүген галим дә, ташчы да , иген үстерүче дә аның олы исеме алдында баш ия, чөнки теләсә нинди һөнәргә юл башы укытучының фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә салына . Ул дөньядагы барлык матур сыйфатларны үзенә туплаган. Киң күңелллелек, тырышлык, балаларга чиксез мәхәббәт, намуслылык... Андагы сабырлык- аналар сабырлыгына тиң.

Уйлап карасаң, укытучы булу җиңел түгел! Минем уйлавымча, чын мөгаллим булыр өчен гомер буе укырга, өйрәнергә, иң мөһиме балаларны яратырга һәм хөрмәт итә белергә кирәктер, мөгаен. Үз һөнәреңне яратып, хезмәтеңә күрә хөрмәтен дә тоеп яшәүдән дә зур бәхет бар микән?!

Кеше гомере – диңгездәге бер тамчы, мәңгелекнең бер мизгеле генә. Шушы кыска гына вакыт эчендә кеше зур - зур планнар кора. Барлык уйлаганын эшләп өлгерергә, җирдә үзенең эзен калдырырга, мәңгелек исем, мәңгелек яшәү алырга тели һәм гомере буе шуңа омтыла.

Бүген без бик тә катлаулы, ыгы-зыгылы, ашыгыч бер чорда яшибез. Кем әйткәндәй, без дөнья куабыз, дөнья безне куа. Кая ашыгабыз? Егылабыз, торабыз, тагын чабабыз, тәгәрәпләр китәбез. Йөгереп эшкә барабыз, йөгереп кайтабыз, мәшәкатьләр белән көннең үткәнен дә сизмибез. Әйдәгез әле, бераз гына булса да туктап бу җиргә ни өчен килгәнебез турында уйланыйк. Без кем? Үзебездән соң ни кала?

...Аллаһы Тәгалә җирләрне һәм күкләрне яралткан һәм ятатылышның иң бөеге итеп, Кешене бар кылган. Кеше башка җан ияләреннән акылы белән аерыла. Балигъ булып үсеп җитү өчен, аңа 16-18 ел гомер кирәк. Шушы чорда ул укырга, язарга, гыйлем тупларга, киләчәктә кем булачагын сайларга тиеш.

... Моннан 23ел элек мин дә, гади авыл кызы, киләчәктә кем булырга дигән сорау алдында туктап калдым. Хыялым – ак халатлы, дөньяны аклыкка күмүче шәфкать туташы булу, яки кешеләр күңеленә белем орлыклары салучы, иң изге һөнәр ияләренең берсе - укытучы булу иде. Әлбәттә, бу һөнәр таләпчән, күп көч, хезмәт, сабырлык сорый торган эш.

Бу хезмәт турында бөек галимебез Каюм Насыйри болай дип язып калдырган: "Укытучы - педагог үзен бөек, изге эшкә алынган кешеләр исәбенә кертергә тиеш. Әгәр син укытучы яки педагог икәнсең, укучыларыңны шулай итеп тәрбиялә ки – син биргән тәрбия укуына якын

тормышында төп юнәлеш булсын.” Шулай ук аның “ Укытучы балаларның күңелендә үзенең әти- әнисенә, туганнарына һәм җәмгыятькә, хезмәткә һәм белгечлеккә мәхәббәт, эшсез буш селкенеп йөрүгә һәм мәгънәсез күңел ачуларга нәфрәт тәрбияләргә тиеш” дигән сүзләре дә укытучының үз эшенә таләпчән итеп карарга тиешлеген искәртә. Әйе, бүгенге тизлек һәм техника заманасында балаларга белем һәм тәрбия бирү ансат эшләрдән булмаганын һәркем аңлый. “Кеше - кеше өчен иң кыйммәтле дару ул“ дигән борынгылар. Укытучыларга карата кулланганда бу гыйбарә аеруча мәгънәле яңгырый. Укытучының шәхси үрнәге, сүзе, киңәше – укучы балалар өчен алыштыргысыз ”дару”. Чыннан да, укытучы укучы өчен идеаллаштырылган бер образ: ул барысын да белә, барысын да аңлый, кирәк икән хәленә керә, юата, киңәш бирә, авыр хәлләрдән йолып кала. Укытучы – иң тугрылыклы, иң ышанычлы кешеләрнең берсе. Яхшы укытучы үз укучысының аз гына уңышын да күреп ала белә, мактап та куя, һәр чак ярдәм итә, үсәргә, камилләшергә мөмкинлек тудыра һәм, киресенчә, “ тискәре”, “ өметсез” кебек сүзләр кулланып , үз укучыларын әнә шул сүзләр белән тиргәгән укытучы балаларның шәхес буларак формалашуына бик начар йогынты ясаганын һәрберебез бик яхшы беләбез. Әлбәттә, эшебездә мәрхәмәтле булып, балаларның һәр теләгенә юл куеп торып булмый. Укыту – тәрбия эшендә һәр төрле кисәтүләр, шелтәләр, хәтта сүзне катырак, кискенрәк итеп әйтү дә булырга мөмкин. Ләкин ни генә булмасын, бер нәрсәне истән чыгармаска кирәк: бала ул – иң беренче чиратта кеше, һәм аның белән нәкъ менә кешеләрчә сөйләшә белү шарт.

Дәрес вакытларында балаларда зирәклелек, тапкырлык, тиз аңлаучанлык һәм үткен фикер йөртергә өйрәтү өчен төрле эш алымнарыннан файдалану кирәк. Укучыны игътибарлы булырга өйрәтү - укытучының төп бурычларыннан берсе. Игътибарлы бала гына теманы дәрестә үзләштерә ала.

Әңгәмә, сорау – җавап, лекция, тематик кичәләр, төрле фән атналыклары - болар берсе дә эзсез калмыйлар. Әлбәттә, мондый чараларның уңышлы узуында укучы балаларның үз тырышлыгы, үз катнашуы бик уңай тәэсир ясаячак. Шунлыктан укучыларның һәрберсенә нинди дә булса аерым эш, йөкләмә башкарырга туры килә. Кечкенәме ул эш, зурмы, әмма һәркемдә бер җаваплы эш була. Моны, соңыннан кичәгә бәя биргәндә, һәркем үз тәэсирен әйтә алсын өчен шулай эшлим.

Укучыга тирән белем бирү һәм алган белемнәрне практикада куллану, бүгенге тормышка әзерләү, һөнәр сайларга булышу, үз фикере булган яшьләр тәрбияләү, бүгенге укытучының төп бурычы дип уйлыйм мин. Шушы сыйфатларны булдыру өчен, укучыларны мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәтү, материалны анализларга, чагыштырырга, исбатларга һәм нәтиҗә ясарга өйрәтергә тырышам. Мөстәкыйль эшләүче укучылар гына класстан тыш эшләрдә актив катнашалар. Мөстәкыйль эшнең формалары бик күп. Аларны дәрестә дә, өйдә дә, дәрестән тыш вакытта да оештырырга мөмкин.

Соңгы елларда тормышның барлык өлкәләренә дә компьютер үтеп керде. Шул ук вакытта уку-укыту системасына да. Заман мәктәбенең тормышын да информацион технологияләрдән башка күз алдына китереп

булмый. Укучыларда уку процессына кызыксыну уяту өчен, стандарт методлар белән генә чикләнергә ярамый. Компьютер технологиясеннән нәтиҗәле файдалану—хәзерге көндә укыту методикасының мөһим бурычы. Дәресләрдә компьютер куллану укучыларның актив һәм аңлап эшләвен тәэмин итүнең яңа алымы буларак дәресне тагын да күрсәтмәле итә. Һәр укучының белем үзләштерүгә сәләте төрлечә була. Кайбер укучыларның ишетеп истә калдыру дәрәҗәсе өстенлек алса, күпчелек укучыларда күреп истә калдыруы өстенлек алган була. Менә шушы вакытта нәкъ компьютер ярдәмгә килә. Укучы бүген укытучыга караганда да күбрәк белә. Әгәр дә элек мәктәп баласы өчен мәгълүмат чыганагы булып китап һәм мөгаллим торса, бүген ул барлык кызыксындырган сорауларга җавапны интернет челтәре аша да таба ала. Әгәр дә укытучы дәрестә күрсәтмәлекне житәрлек дәрәҗәдә кулланса, төрле уен ситуацияләре, сөйләм күнегүләре, инновацион технология элементларыннан дөрес файдалана белсә, ул, һичшиксез, эшендә уңышка ирешәчәк.

Тәрбия һәм укыту барышында укытучының һәм класс җитәкчесенең төп таянычыларының берсе - ата-аналар. Алар белән очрашып тору, яңалыкларны җиткерү – безнең төп бурыч. Шушы очрашу вакытында иң элек бала характерындагы уңай, өметле якларны әйтүне онытмаска кирәк дип уйлыйм. Чөнки һәр ата- ананың үз баласын яхшы итеп, тормышка яраклы шәхес итеп күрәсе килә.

Укучы мәктәпне тәмамлап, нинди генә кеше булып китсә дә, укытучы өчен аның баласы булып кала. Ул аның уңышларына сөенә, уңышсызлыклары өчен йөрәге аша көенә. Әйе, без яшь үстергән агач черек булмасын, тамырлары нык, тирән, җәмгыятьнең төрле җил-давылларына чыдам булсын иде.